ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление**
№ 270

**Карар**
от «17» 07 2024 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 23 августындагы 274 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлегенә вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 23 августындагы “Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында 274 номерлы карарына (алга таба-Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Түбәндәгеләрне үз көчен югалтты дип танырга:

1.1.1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021елның 23 августындагы N 274 номерлы карары белән расланган Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (2 нче кушымта);

1.1.2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021елның 23 августындагы N 274 номерлы карары белән расланган Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ (5 нче кушымта);

1.1.3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021елның 23 августындагы N 274 номерлы карары белән расланган Рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (10 нчы кушымта).

2. Опубликовать Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Мамадыш муниципаль районының

0000012273

рәсми сайтында http://mamadysh.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.М. Никифоровка йөкләргә.

Җитәкче В.И.Никитин